| | |
|---|---|
| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «КУАКБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «КУАКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

2024 елның 10 июле №20

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында

«Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Ветеринария турында» 1993 елның 4979-1 номерлы РФ Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге Советының 2015 елның 20 ноябрендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәреш кертергә:

«Йорт хайваннарын һәм кошларын тоту» бүгене 132 пункттан 155 пунктка кадәр төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы, К.Маркс ур., 15; Сходнево-Чертанлы авылы - Ирек ур., 5б йорт, авыл мәдәният йорты бинасы; Чүте авылы - Тынычлык урамы, 8а йорт, авыл клубы бинасы адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә; Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

3. . Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Әхмәтжанова